КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 15 декабрь г.Казань № 1087

«Минзәлә муниципаль районында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Тургай» социаль приюты» дәүләт казна учреждениесен бетерү турында

Татарстан Республикасының социаль яклау тармагы инфраструктурасын оптимальләштерү һәм Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының нәтиҗәлелеген арттыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 423721, Татарстан Республикасы, Минзәлә районы, Иске Матвеевка авылы, Больничная урамы, 7 нче йорт адресы буенча урнашкан «Минзәлә муниципаль районында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Тургай» социаль приюты» дәүләт казна учреждениесен (алга таба – Социаль приют) бетерү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

эш көннәрендә исәпләнә торган 14 көн эчендә:

Социаль приютның бетерү комиссиясе составын расларга;

Социаль приютны бетерү тәртибен һәм срокларын Россия Федерациясе Граждан кодексы нигезендә билгеләргә;

Социаль приютны бетерү турында карар кабул ителгәннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына кертү өчен теркәү органына Социаль приютның бетерү процессында булуы турында белешмә бирергә;

эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә бетерелә торган учреждениегә оператив идарә хокукында беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен, шул исәптән күчемсез мөлкәтен алга таба файдалану турындагы тәкъдимнәрне

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына кертергә;

бетерү аркасында эштән азат ителә торган хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә тәэмин итәргә, шулай ук Социаль приютны бетерү буенча законнарда каралган башка чараларны гамәлгә ашырырга.

3. Социаль приют йөкләмәләре буенча, шул исәптән суд карарларын үтәү нәтиҗәсендә барлыкка килгән йөкләмәләр буенча җаваплы, Социаль приютны бетерү процедурасын гамәлгә ашыру өчен җаваплы республика башкарма хакимият органы – Социаль приютны гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына әлеге карарның 2 пунктының алтынчы абзацында күрсәтелгән мөлкәт исемлеген алганнан соң эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен, шул исәптән күчемсез һәм аеруча кыйммәтле мөлкәтен алга таба файдалану турында бирелгән тәкъдимнәргә нигезләнеп, Социаль приютка оператив идарә хокукында беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен тапшыруны, 16:28:140101:179 кадастр номерлы җир кишәрлеген даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукын туктатуны тәэмин итәргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин